**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГлаваЮлсубинского сельского поселения**
**Рыбно-Слободского муниципального района**
Индекс 422669 с.Юлсубино ул.Татарстан дом 56а
телефон

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Балык Бистәсе муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Башлыгы**
индекс 422669 Юлсубино авылы Татарстан ур. 56а йорт
телефон

Тел.: (84361) 30223, факс: (84361) 30223, эл.адрес: Uls.Rs@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

от 17.10.2019 2019 года Юлсубино №1

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Юлсубино авыл җирлегенең Юлсубино һәм Ямаш авыл торак пунктынларында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 45-ЗРТ номерлы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Юлсубино авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 22 маддәсе нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Юлсубино авыл җирлегенең Юлсубино авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыенының беренче этабын 2019 елның 28 октябрендә14 сәг. 00 минутка билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Юлсубино авыл җирлегенең Юлсубино авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыенының икенче этабын 2019 елның 30 октябрендә 14 сәг. 00 минутка билгеләргә.
3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Юлсубино авыл җирлегенең Ямаш авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыенының беренче этабын 2019 елның 29 октябрендә14 сәг. 00 минутка билгеләргә.
4. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Юлсубино авыл җирлегенең Ямаш авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыенының икенче этабын 2019 елның 31 октябрендә 14 сәг. 00 минутка билгеләргә.
5. Гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлү территориаль билге буенча гамәлгә ашырылуын расларга.
6. Гражданнар җыены каравына куела торган сорауны расларга:

Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Юлсубино авыл җирлегенең Юлсубиноһәм Ямаш авыллары торак пунктларында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына

йөреп укучы студентлардан гайре) 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- Ямаш,Юлсубино авылында юллар ремонты өчен вакланган таш сатып алуга
- су белән тәэмин итү
- кышкы чорда Юлсубино һәм Ямаш авылларында юлларны карап торуга:
- Ямаш авылында йортларга урам исемнәре һәм йорт номерларын яздыру
- Юлсубино аылы мәдәният йортына биллиард һәм башка кирәкле җиһазлар алуга
- Чишмәләр төзекләндерүгә

“ЯКЛЫЙМ” “КАРШЫ”

6. Әлеге карарны дәүләт теркәвеннән соң Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Юлсубино авыл җирлегенең түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында урнаштырырга: Юлсубино авылы, Татарстан урамы, 56а йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда.

7. Карар басылып чыккан (халыкка белдерелгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Юлсубино авыл җирлеге башлыгы Х.Х.Гатиятов